# КАТИНКА ХОССУ – 400 МЕТР АРАГА КОМПЛЕКСЛЫ ЙӨЗҮДӘ ДӨНЬЯ ЧЕМПИОНКАСЫ

09.08.2015, 19:18

СПОРТ

**Бу минутларда Су спорт төрләре буенча 16 нчы ФИНА дөнья чемпионатының соңгы ярышлар көне кысаларында алтынчы финал йөзеше төгәлләнде. 400 метр арага комплекслы йөзүдә дөньяның иң көчле 8 спортчы кызы ярышты.**

400 метр арага комплекслы йөзүдә алтын медальне Венгрия кызы, бу араны йөзүдә 4:30.39 секундлы нәтиҗә күрсәткән Катинка Хоссу алды. Аның артыннан финишка америкалы Ди Радо Майя килде, аның нәтиҗәсе - 4:31.71 секунд. Призерлар өчлеген канадалы Эмили Оверхолт япты, бу спортчы күрсәткән вакыт - 4:32.52 секунд.

Хатын-кызлар.Комплекс, 400 м.

1. Катинка Хоссу (Венгрия) – 4:30.39.

2. Ди Радо Майя (АКШ) – 4:31.71.

3. Эмили Оверхолт (Канада) - 4:32.52

9 август. Казан. “Казан Арена”

Су спорт төрләре буенча 16 нчы дөнья чемпионаты Оештыру комитеты матбугат хезмәте

ЯҢАЛЫКЛАР ТАСМАСЫН АЧАРГА